Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

27 июнь 2022 ел | № 21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең 2021нче елның 08нче ноябрендә кабул ителгән 33нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибен раслау турында” карарына үзгәреш кертү

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 26 статьясы нигезендә, коррупциоген нормаларны бетерү максатларында, Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең 2021 елның 08 ноябрендә кабул ителгән 33нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибен раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 16. Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу.

1. Конкурс сайлап алуны комиссия башкара.

2. Конкурс сайлап алу критерийлары, аларның әһәмияте, аларга тиешле баллар һәм үлчәү коэффициентлары 1 нче кушымтада (алга таба – критерийлар) билгеләнгән.

3. Конкурс сайлап алу әлеге Тәртипнең 14 статьясы нигезендә үткәрелә торган комиссия утырышында башкарыла.

4. Комиссия инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны узган инициативалы проектларны ачыклау критерийлары нигезендә бәяләүне гамәлгә ашыра.

5. Конкурс нәтиҗәләре буенча йомгаклау бәясен исәпкә алып, комиссия инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны узган яисә узмаган дип игълан итү турында карар кабул итә.

6. Барлык критерийлар буенча максималь суммалы балл җыйган конкурс сайлап алуын узган инициатив проект игълан ителә.».

1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә әлеге карарга кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес

буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/saba адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2022 елның 27 июнендәге 21 номерлы карарына 1 номерлы кушымта

Конкурс сайлап алу критерийлары

| N т/б | Критерий исеме | Критерий буенча баллар |
|---|---|---|
| 1 | **Актуаль (кискен) проблемалар** | |
| бик югары - проблема халык тарафыннан критик дип бәяләнә, проблеманы хәл итү халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү һәм саклау өчен кирәк | | 10 |
| югары - проблема халык тарафыннан шактый бәяләнә, аны хәл итмәү тормыш сыйфатына тискәре йогынты ясаячак | | 7 |
| уртача - хезмәт проблемасы халык тарафыннан актуаль дип бәяләнә, аны хәл итү тормыш сыйфатын яхшыртуга китерергә мөмкин | | 4 |
| 2 | **Проектны тормышка ашыруга комплекслы якын килү** | |
| әйе | | 10 |
| юк | | 0 |
| 3 | **Халыкның аз керемле төркемнәре өчен инициативалы проектның җайлашуы** | |
| әйе | | 10 |
| юк | | 0 |
| 4 | **Количество граждан, поддержавших инициативный проект** | |
| 500дән артык кеше | | 10 |
| 250 дән 500 гә кадәр кеше | | 7 |
| 50дән 250 гә кадәр кеше | | 5 |
| 50гә кадәр кеше | | 3 |
| 5 | **Инициативалы проект нәтиҗәләрен карап тоту (саклап калу) максатларында киләсе чорларда бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру зарурилыгы** | |
| әйе | | 10 |
| юк | | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| **6** | **Оригинальлек, креативлык** | |
| әйе | | 10 |
| юк | | 0 |
| **7** | **Инновацион технологияләр, яңа техник карарлар куллану** | |
| әйе | | 10 |
| юк | | 0 |
| **8** | **Гаризада презентацион материаллар, дизайн-проект булу** | |
| әйе | | 10 |
| юк | | 0 |
| **9** | **Инициативалы проектны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда җәмәгатьчелекнең катнашуы** | |
| **9.1** | **Инициативалы проектның гомуми бәясеннән инициативалы түләүләр өлеше** | |
| инициативалы проектның гомуми бәясенең 20% нан | | 10 |
| инициативалы проектның гомуми бәясенең 15% тан 20 % ка кадәр | | 8 |
| инициативалы проектның гомуми бәясенең 10% тан 15 % ка кадәр | | 5 |
| инициативалы проектның гомуми бәясенең 0% тан 10% ка кадәр | | 1 |
| **9.2** | **Инициативалы проектны тормышка ашыруда мөлкәт һәм (яки) хезмәт катнашуы** | |
| әйе | | 5 |
| юк | | 0 |